КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 ноябрь г.Казань № 988

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1084 нче карары белән расланган 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1084 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 июль, 619 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Программаның VIII бүлегендәге 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Медицина оешмасы, шул исәптән сәламәтлек саклауның хосусый системасындагы Программаны тормышка ашыруда катнашмый торган медицина

оешмасы тарафыннан гражданнарга медицина ярдәмен ашыгыч рәвештә түләүсез күрсәтүгә бәйле чыгымнар Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы буенча медицина ярдәме өчен түләү турындагы тариф килешүе һәм Мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина оешмаларын нигездә берканаллы финанслауны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләү тарифларын һәм тәртибен билгеләү турындагы тариф килешүе белән билгеләнгән тәртип һәм күләмнәр нигезендә каплана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин